ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дмитрова, д.2,
с.Ютаза, 423962

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Дмитров урамы, 2 йорт,
Ютазы авылы, 423962

Тел.:(85593) 4-00-91, факс:4-00-93, e-mail: Utaz.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 4 29.01.2015 ел

Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2014 елның 23 октябрендәге "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында"гы 39 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2014 елның 31 декабрендә 2013 елның 28 декабрендәге «Россия Федерациясе чикләрендә хәрәкәт итү, яшәү урынын сайлау ирегенә Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 387 –ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсе законлы көченә керү сәбәпле һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану һәм Ютазы районы прокурорының 2015 елның 12 гыйнварындагы 02-08-01-2015 санлы протестын исәпкә алып

1. Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2014 елның 23 октябрендәге "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында"гы 39 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Башкарма комитетында белешмә(өземтә) бирү буенча хезмәт күрсәтү административ регламентының 1 нче кушымтасына муниципаль хезмәт күрсәтү стандартының 2.5 пункты «муниципаль хезмәт күрсәтү алу өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган документларның тулы исемлеге» 2 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Яшәү урыныннан белешмә, йорт китабыннан өзекләр, элеккеге яшәү урыныннан белешмәләр алу өчен:

1.1. Шәхесне раслаучы документлар.
1.2. Йорт китабы.
1.3. Шәхси торак йортка хокуклар турында Документ (хокукны дәүләт теркәве турында таныклык яисә шәхси торак йортка техник (кадастр) паспорт, яисә Ростехинвентаризациядән хокук ияләре турында белешмә-Федераль БТИ, Татарстан Республикасы буенча филиал).

2.Гаилә составы турында белешмә алу өчен:
2.1. Шәхесне раслаучы документлар.
2.2. Йорт китабы.

2.3. Соралган адрес буенча теркәлгән барлык гаилә әгъзаларының туганлыгын раслаучы документлар (паспортлар, туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык).

3.Үлем көнендә үлгән кешенең яшәү урыныннан белешмә алу өчен:

3.1. Шәхесне раслаучы Документ.
3.2. Йорт китабы.
3.3. Үлем турында таныклык (оригинал).
3.4. Соралган адрес буенча теркәлгән барлык гаилә әгъзаларының туганлыгын раслаучы документлар (балалар туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык).

4.Хуҗалык китабыннан өзек алу өчен:

4.1.хуҗалык китабы ннан өзек бирү турында ирекле формада гариза;
4.2. Хокук иясенең шәхесен раслаучы документ;
4.3.үлгән җир участогы хуҗасының үлем таныклыгының күчермәсе;
4.4.җир кишәрлегендә урнашкан йортка (башка объектлар булса) хокук билгеләүче документларның күчермәләре;
4.5. җир участогында урнашкан йортның адрес номеры күрсәтелгән фотосы.

5.Физик зат вәкиле өчен гариза бирүче исеменнән гамәлләр башкару вәкаләтләрен раслаучы нотариаль расланган документның күчермәсен тапшырырга кирәк.
6.Исемдә китерелгән Документлар документларның тиешле оригиналы белән бергә тапшырыла.
7.Гаризалар, документлар һәм документларның күчермәләре бер экземплярда бирелә.»

2. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының Интернет челтәрендәге мәгълүмат стендында һәм рәсми сайтында бастырып чыгарырга www.yutaza.tatar.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Ютазы авыл җирлеге башкарма комитет вазыйфаларын башкаручы Г.Г.Сәфиуллина